ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларының (карарлар нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ант итү тәртибен раслау турында» 2000 елның 29 июнендәге 207 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына кушымтаның беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 6 (5); 2014, № 6 (III өлеш); 2016, № 5), «сайланган» сүзен «билгеләнгән» сүзенә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләрен раслау турында» 2003 елның 17 июлендәге 2167 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләренең 8 статьясына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 7; 2007, № 12 (IV өлеш); 2009, № 5), «хөрмәтле Президент» сүзләрен «хөрмәтле Рәис» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты таныклыгы һәм «Татарстан Дәүләт Советы депутаты» күкрәк тамгасы, аларның үрнәкләре һәм тасвирламалары турында нигезләмәләр хакында» 2004 елның 26 февралендәге 2643 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты таныклыгы турында нигезләмәнең 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (II өлеш); 2007, № 12 (IV өлеш); 2011, № 1 – 2 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Президенты»

сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. «Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе турында нигезләмә хакында» 2004 елның 3 июнендәге 155-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы түбәндәге редакциядә бирергә:

«Татарстан Республикасы Конституциясенең 80 статьясы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 34 һәм 35 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карар бирә:»;

2) Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе турында нигезләмәдә:

а) 1 пунктта «101, 103» саннарын «35» санына алмаштырырга;

б) 8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

5. «Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау хакындагы нигезләмә турында» 2011 елның 7 июлендәге 1739-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау хакында нигезләмәнең 2 пунктындагы 1 пунктчасына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 7; 2012, № 10 (II өлеш), «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

6. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында» 2015 елның 16 апрелендәге 551-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламентаризм үсешенә өлеш керткән өчен» мактау билгесе турында

нигезләмәгә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзалары» сүзләрен «Россия Федерациясе сенаторлары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 пунктның 2 пунктчасындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмәнең 20 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2019, № 7 – 8, № 12; 2022, № 11), «ведомстволары» сүзен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары структурасына керә торган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

8. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларын төзү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 12-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2019, № 9, №10; 2021, № 3, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) утыз өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

2) җитмеш өченче абзацта «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

9. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Президентының ант итү тәртибен раслау турында» 1996 елның 28 мартындагы 484 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 3);

2) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламент хәбәрләре» («Парламентские вести») мәгълүмат бюллетенен нәшер итү турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1871 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12);

3) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламент хәбәрләре» («Парламентские вести») мәгълүмат бюллетенен нәшер итү турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1871 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2000 елның 24 мартындагы 111 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3);

4) «Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының ант итү тәртибен раслау турында» 2000 елның 29 июнендәге 208 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 6 (5);

5) «Татарстан Республикасы Конституция комиссиясе турында» 2001 елның 20 сентябрендәге 1010 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 9);

6) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламент хәбәрләре» («Парламентские вести») мәгълүмат бюллетенен нәшер итү турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1871 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 елның 15 декабрендәге 2457 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 12 (II өлеш);

7) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламент хәбәрләре» («Парламентские вести») мәгълүмат бюллетенен нәшер итү турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1871 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 28 апрелендәге 73-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5);

8) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламент хәбәрләре» («Парламентские вести») мәгълүмат бюллетенен нәшер итү турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1871 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 13 октябрендәге 442-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 10);

9) «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән эш итү өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясен төзү турында» 2004 елның 25 октябрендәге 507-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 10);

10) «Татарстан Республикасы законнарының гамәлдә булу нәтиҗәлелеге турында» 2007 елның 5 июлендәге 3045-III ДС номерлы

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (III өлеш);

11) «Татарстан Республикасы законнарының гамәлдә булу нәтиҗәлелеге турында» 2007 елның 5 июлендәге 3045-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы законнарының гамәлдә булу нәтиҗәлелеге турында»гы мәсьәләне өйрәнү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 28 февралендәге 3527-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 2);

12) «Татарстан Республикасы Конституция судында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле турында» 2009 елның 22 апрелендәге 89-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 4);

13) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламент хәбәрләре» («Парламентские вести») мәгълүмат бюллетенен бастырып чыгару турында» 2009 елның 22 апрелендәге 93-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 4);

14) «Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының ант итү тәртибен раслау турында» 2000 елның 29 июнендәге 208 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәреш кертү хакында» 2009 елның 8 июлендәге 299-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш);

15) «Законнар һәм хокук куллану практикасы мониторингы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе турында» 2017 елның 16 февралендәге 1627-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2017, № 1 – 2);

16) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 8 ноябрендәге 2021-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 2 һәм 3 пунктларын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2017, № 11);

17) «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым комиссияләре составына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 20 февралендәге 2178-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 4 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2018, № 1 – 2);

18) «Законнар һәм хокук куллану практикасы мониторингы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составындагы үзгәрешләр турында» 2019 елның 18 мартындагы 2797-V ДС номерлы

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2019, № 3).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2010-VI ДС